**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**НУРЛАТСКИЙ**
**МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН**
**ГЛАВА ЕГОРКИНСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ**
**РАЙОНЫ**
**ЕГОРКИНО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**БАШЛЫГЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Егоркино ав. **КАРАР**

«11» ноябрь 2025 ел № 8

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Егоркино авыл җирлегенең Рус Мәнҗесе авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45 статьясы нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының «Егоркино авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Егоркино авыл җирлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2025 елның 27 ноябрендә 15 сәгать 00 минутта Рус Мәнҗесе авылында Октябрьская урамы буенча 17нче йорт янында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Егоркино авыл җирлегенең Рус Мәнҗесе авылында Октябрьская урамы буенча №1-17, 2-18нче йортлардан үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының беренче этабын уздыруны билгеләргә.

2. 2025 елның 27 ноябрендә 15 сәгать 30 минутта 1-я Набережная урамы буенча 12нче йорт янында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Егоркино авыл җирлегенең Рус Мәнҗесе авылында Беренче Яр буе урамы 1-27 нче йортттан, 2-24нче йорттан, Икенче Яр буе урамы буенча 1-35нче йортларда яшәүчеләрдән үзара салым кертү, элек расланган карарларга үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Халык җыенының икенче этабын уздыруны билгеләргә.

3. Гражданнар җыенын уздыру өчен Рус Мәнҗесе авылында яшәүчеләрнең исемлеген аеруны сайлау тәртибен территориаль билге буенча башкарырга.

4. Гражданнар җыены этапларын үткәрү һәм оештыру эше Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Егоркино авыл җирлеге башлыгы һәм Башкарма комитеты тарафыннан башкарыла.

5. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2026 елда Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Егоркино авыл җирлегенең Рус Мәнҗесе авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, Бөек Ватан сугышында катнашучы тол хатыннардан, 1 төркем инвалидлардан тыш, 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы:

- урамнарны яктырту җайланмасы;
- су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту.»

«РИЗА» «КАРШЫ».

6. Әлеге карарны «Интернет «мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (игълан итәргә), Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru урнаштырырга, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Каравыл Тавы авылы мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына 10 көннән дә соңга калмыйча урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

7. Әлеге карар аның басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Егоркино авыл җирлеге башлыгы А.И. Борисов